**ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ**
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы
Бәйрәкә-Тамак авыл җирлеге составына керүче
Бәйрәкә-Тамак торак пунктында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**19.11.2022 ел** **№ 1**

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, 2022 елның 19 ноябрендә узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2023 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә-Тамак авыл җирлеге составына керүче Бәйрәкә-Тамак торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш, һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә сез ризамы:

- Бәйрәкәтамак бистәсендә зират территориясен киртәләүне ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү);
- Бәйрәкәтамак бистәсендә чишмә территориясен төзекләндерү ( төзелеш материаллары сатып алу, каптажны ремонтлау, торбаларны алыштыру, буяу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү),;
- авыл эчендәге юлларны карап тоту (грейдер белән узу, кардан чистарту, килешү буенча түләү)” соравы буенча.

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 213 кеше кертелгән, тавыш бирүдә 110 кеше катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында 110 катнашучы «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены түбәндәге карар чыгарды:

1. Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә-Тамак авыл җирлеге Бәйрәкә-тамак торак пунктында халык җыены узды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.

2.Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә-Тамак авыл җирлеге территориясендә Бәйрәкә-Тамак авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме?:

- Бәйрәкәтамак бистәсендә зират территориясен киртәләүне ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү);
- Бәйрәкәтамак бистәсендә чишмә территориясен төзекләндерү ( төзелеш материаллары сатып алу, каптажны ремонтлау, торбаларны алыштыру, буяу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү),;
- авыл эчендәге юлларны карап тоту (грейдер белән узу, кардан чистарту, килешү буенча түләү).” буенча сорауны кабул ителгән дип танырга.

3. Бәйрәкә-Тамак авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халык җыены нәтиҗәләрен халыкка игълан итәргә һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында (http://jutaza.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән 5 көн эчендә бастырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкә-Тамак авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен юлларга.

Җыенда рәислек итүче
Бәйрәкә-Тамак авыл җирлеге башлыгы: Ф.В.Әхмәтов